# Күкнең җиденче катында

Балалар һәм яшүсмерләр
газетасы
Март, 2021




Кадерле хатын-кызлар - әниләр, әбиләр, апалар, сеңелләр! Сезне чын күңелдән 8 Март бәйрәме белән котлыйбыз. Сезгә иң изге теләкләр телибез, якыннарыгызның игелеген күреп яшәргә насыйп итсен сезгә Ходай. Салкын, озын кышлардан соң килгән бу беренче Яз бәйрәме, иң гүзәл бәйрәмнәрнең берсе. Бу бәйрәм сезгә тормыш яме, яшәү көче өстәсен. Бәхет нурында коенып, назга күмелеп, сөеп-сөелеп яшәгез. Бәйрәм белән!!!

## Хатын-кызга мәдхия

Хатын-кызлар – гүзәл затлар –
Сез ханымнар һәм туташлар.
Һәммәгез дә чибәркәйләр:
Җиләк ирен, кыйгач кашлар,

Озын толым, зифа буйлар,
Серле күзләр, ут карашлар... –
Сез барчагыз безнең өчен
Иң кыйммәтле асыл затлар.

Горур да сез, назлы да сез,
Тау кыядай, буй җитмәслек.
Гүзәл, затлы, чибәр, нәфис -
Гөлләр белән тиңләшмәслек.

Язның тәүге бәйрәмедәй
Нечкә күңел, хисле бит сез.
Саф сөюле, көләч йөзле,
Яз кояшы төсле бит сез.

Әй хатын-кыз - илаһи зат,
Ир-ат сиңа гел табына.
Гаиләнең тотнагы син –
Баш иямен мин каршыңда.

Муса Көекле

## Әнием-назлы гөлем.

Минем әниемнең исеме – Гөлназ. Исеменең мәгънәсе “назлы гөл”. Әниемне гөлләр белән чагыштырып була, ул көннән-көн яшәрә, чибәрләнә.

Әбием аңа Миләүшә исеме бирергә теләгән була, ләкин апасының кызы үз сүзендә нык тора: Гөлназ исемен куштыра. Әниемнең әйтүе буенча, ул үскәндә бик популяр исем була, сыйныфында 4 Гөлназ укый.

Әнием тумышы белән Балтач якларыннан. Белемне Балтач мәктәбендә ала. Мәктәпне яхшы билгеләргә тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты һәм чит телләр факультетына укырга керә. 3 ел укыгач, әнием Казанның бер мәктәбендә укытучы булып эшкә урнаша. 2 елдан диплом алып, шул мәктәптә үзенең укучылары белән эшләп кала.

Әнием кечкенәдән балаларны бик ярата. Хыялы-балалар белән эшләү була.

Хәзерге көндә кечкенә вакытындагы хыялы тормышка ашты, балалар бакчасында эшли. Үз эшенә карата бик төгәл. Гел эзләнә, яңалыкка омтыла. Әле кечкенә балаларына күп мәгълумат бирергә, барысына өйрәтергә, тормышка карата мәхәббәт тәрбияләргә ашыга.

Өйдә әнием таләпчән, безнең, 3 баласының, укымышлы, тәртипле, тыйнак, эшчән булуыбызны тели. Төрле халык ашлары пешереп сыйлый, гөлләр үстерә. Җәй көне бакчада эшләргә ярата, яшелчәләр үстерә, көз көне бай уңыш ала.

Бәйли, чигә, өйдә дә гел яңалык кертеп тора.

Без әниебезне бик яратабыз. Ул дөньяда шундый бер генә.

Асланова Нәргиз, 7 нче сыйныф

# Күп укыган-күп белер

Мәктәбебездә китаплар бирешү традициясе дәвам итә. Укучылар бер-берсенә матур эчтәлекле китаплар бүләк итеп, фотога да төштеләр.











8 нче март бәйрәме мәктәбебездә бик күңелле узды. Укучыларыбыз бәйрәмгә бик ныклап әзерләнгәннәр иде.
Матур теләкләр язылган чәчәкләр, укытучыларны матур җырлар белән каршы алу... Җанлы концерт…

Ир-атлар, егетләр күңелләрдә менә шундый онытылмаслык бәйрәм мизгелләре калдырдылар...









# Гәҗитне басмага әзерләделәр:

Баш мөхәррир: Габдуллаҗанова А.Ф.
.

8а сыйныфы укучылары:
Соколова С., Сафина К., Овезова Л., Закирова А.